Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

КАРАР №L-2

Балык Бистәсе штп.

2024 елның 30 июле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2022 елның 7 июлендәге "Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына акчалата бүләкләүләр, вазыйфаи эш хаклары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында"гы XXII-3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларның хезмәтенә түләү системасы үзгәрүгә бәйле рәвештә, муниципаль хезмәткәрләрнең, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга социаль гарантияләрне тәэмин итү, хезмәт өчен түләүне тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларында, "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 22 маддәсе, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 26 маддәсе, "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында" 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, контроль-хисап органнары рәисләренә, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында" 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары, "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә күпьеллык хезмәт өчен пенсиягә чыгу сәбәпле бер тапкыр бирелә торган кызыксындыруны түләү тәртибе турында" Нигезләмәне раслау хакында 2005 елның 29 декабрендәге 666 номерлы карары, «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасыннан пенсиягә чыгу сәбәпле Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләүне түләү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 10 июлендәге 353 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләрнең, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен

гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2022 елның 7 июлендәге “Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына акчалата бүләкләүләр, вазыйфаи эш хаклары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында”гы XXII-3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының контроль-хисап органы рәисенә, рәис урынбасарына, аудиторларына хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары» 1 нче кушымтасын кушымта итеп бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә;

1.2) «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи айлык эш хаклары күләмнәре» 3 нче кушымтасын кушымта итеп бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә;

1.3) «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренә ай саен акчалата кызыксындыруны түләүне гамәлгә ашыру күләмнәре һәм тәртибе» 7 нче кушымтасындагы «1» цифрын «41»цифрларына алыштырырга;

1.4) «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә вакытлыча булмаган хезмәткәрнең вазыйфаларын үтәгән өчен компенсация түләүләрен билгеләү һәм исәпләү күләмнәре һәм тәртибе» 14 нче кушымтасына түбәндәге эчтәлектәге 2.4 пунктчасын өстәргә:

«2.4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы вазыйфаларын башкарган өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы урынбасарына компенсация түләве Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы урынбасарының Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы вазыйфаларын башкару чорында аларның акчалата тәэмин ителешләре аермасы рәвешендә билгеләнә.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкарган өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына компенсация түләве Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарының Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе

вазыйфаларын башкару чорында аларның акчалата тәэмин ителешләре аермасы рәвешендә билгеләнә.»;

1.5) «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру тәртибе» 17 нче кушымтасындагы «1» цифрын «41» цифрларына алыштырырга;

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә үз хокукый актларын әлеге карарга туры китерүне йөкләргә.

3. Карарның 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагылуын билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

Р.Р. Ислямов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2022 елның 7 июлендәге
XXIII-3 номерлы карарына
Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2024 елның 30 июлендәге
L-2 номерлы карары
редакциясендә
кушымта №1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының контроль-хисап органы рәисенә, рәис урынбасарына, аудиторларына хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары

| Вазыйфаның аталышы | Акчалата бүләкләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | 8 төркем |
| Муниципаль район Башлыгы | 35272 |
| Муниципаль район Башлыгы урынбасары | 31745 |
| Муниципаль районның Контроль-хисап органы рәисе | 31745 |
| Муниципаль районның Контроль-хисап органы рәисе урынбасары | 28511 |
| Муниципаль районның Контроль-хисап органы аудиторы | 24248 |

Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларын акчалата бүләкләү күләмнәрен билгеләү өчен тиңдәшле рәвештә муниципаль берәмлек статусына һәм аның территориясендә даими яшәүче халык санына карап, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен хезмәткә түләү төркемнәренә кертү күрсәткечләре кертелә.

Күрсәтелгән күрсәткечләргә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының "Балык Бистәсе муниципаль районы" муниципаль берәмлеге сигезенче төркемгә кертелде – башка муниципаль районнар халык санына бәйсез рәвештә.

2009 елның 12 февралендәге "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру

гарантияләре турында”15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль вазыйфаны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында даими нигездә биләүче затка (алга таба – муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче зат) Татарстан Республикасы норматив актлары белән башкасы каралмаган очракта айлык акчалата бүләкләүдән (хак түләүдән) гайре өстәмә рәвештә билгеләнә:

1) матди ярдәм;

2) ай саен акчалата кызыксындыру;

3) эш нәтиҗәләре буенча премия;

4) еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү;

5) федераль законнар һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр.

Муниципаль район Башлыгына, еллык түләүле отпуск биргәндә айлык акчалата бүләкләүдән һәм бер мәртәбә түләүдән тыш, ай саен акчалата кызыксындыру, эш нәтиҗәләре буенча премияләр түләнә, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр дә башкарылырга мөмкин. Шул ук вакытта муниципаль район Башлыгына айлык акчалата түләүләрнең җыелма күләме Татарстан Республикасы министрына акчалата түләүләрнең 0,9 айлык җыелма күләменнән артык була алмый.

Муниципаль район Башлыгы урынбасарына, айлык акчалата бүләкләүдән һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер мәртәбә түләүдән тыш, өстәмә рәвештә айлык акчалата кызыксындырулар, эш нәтиҗәләре буенча премияләр түләнә ала, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр башкарыла ала. Шул ук вакытта муниципаль район Башлыгы урынбасарының айлык акчалата түләүләренең гомуми күләме муниципаль район Башлыгының айлык акчалата түләүләренең 0,55 күләменнән артык була алмый.

Муниципаль районның контроль-хисап органы рәисенә, айлык акчалата бүләкләүдән һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер мәртәбә түләүдән тыш, өстәмә рәвештә айлык акчалата кызыксындырулар, эш нәтиҗәләре буенча премияләр түләнә ала, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр башкарыла ала. Шул ук вакытта аның айлык акчалата түләүләренең гомуми күләме муниципаль район Башлыгының айлык акчалата түләүләренең 0,55 күләменнән артык була алмый.

Муниципаль районның контроль-хисап органнары рәисләре урынбасарларына, айлык акчалата түләүдән һәм еллык түләүле отпускны биргәндә бер мәртәбә түләүдән гайре айлык акчалата кызыксындырулар, эш нәтиҗәләре буенча премияләр өстәмә түләнә, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр башкарыла ала. Шул ук вакытта аларның акчалата түләүләренең айлык җыелма күләме муниципаль районның контроль-хисап органы рәисенең айлык акчалата түләүләренең 0,8 күләменнән артык була алмый.

Муниципаль районның контроль-хисап органнары аудиторларына, айлык акчалата түләүдән һәм еллык түләүле отпускны биргәндә бер мәртәбә түләүдән гайре айлык акчалата кызыксындырулар, эш нәтиҗәләре буенча премияләр өстәмә түләнә, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр башкарыла

ала. Шул ук вакытта аларның акчалата түләүләренең айлык җыелма күләме муниципаль районның контроль-хисап органы рәисенең айлык акчалата түләүләренең 0,6 күләменнән артык була алмый.

Муниципаль район Башлыгына, муниципаль район Башлыгы урынбасарына, муниципаль районның контроль-хисап органы рәисенә, рәис урынбасарына, аудиторларына еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү айлык акчалата бүләкләүдән артмаган күләмдә түләнә.

Муниципаль район Башлыгы урынбасарына, муниципаль районның контроль-хисап органы рәисенә, рәис урынбасарына, аудиторларына матди ярдәм бала туганда, тантаналы, юбилей яки истәлекле датага, шулай ук сайланган вазыйфаи затның һәм (яисә) аның якын туганнарының көчле чир белән авыруы, үлеме һәм башка бәхетсезлек очраклары булганда түләнергә мөмкин. Матди ярдәм күрсәтү хезмәт өчен түләү фондын экономияләү исәбенә башкарыла, матди ярдәмне түләү өчен нигез булып муниципаль район Башлыгы боерыгы белән муниципаль район Башлыгы урынбасарына, муниципаль районның контроль-хисап органы рәисенә, муниципаль районның контроль-хисап органы рәисе урынбасарына һәм муниципаль районның контроль-хисап органы аудиторларына карата муниципаль район Башлыгы күрсәтмәсе белән рәсмиләштерелгән муниципаль хокукый акт тора.

Муниципаль район Башлыгы урынбасары, муниципаль районның контроль-хисап органы рәисе урынбасарына, аудиторларына, аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләргә муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларның хезмәтенә түләү фонды чикләрендә түләнә һәм максималь күләмнәр белән чикләнми. Премиянең конкрет күләме бүләкләү турындагы муниципаль хокукый актта күрсәтелә.

Муниципаль район Башлыгы урынбасары, рәис, рәис урынбасары, муниципаль районның контроль-хисап органы аудиторлары Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең социаль-икътисадый үсешендә нәтиҗәләргә ирешүгә керткән өлешләре өчен дә бүләкләнергә мөмкин, шулай ук дәүләт, муниципаль яки һөнәри бәйрәмнәр, истәлекле яки юбилей даталары белән бәйле рәвештә җирле бюджет акчалары хисабына.

Муниципаль район башлыгы урынбасарына, рәисенә, рәис урынбасарына, муниципаль районның контроль-хисап органы аудиторларына премия түләү өчен нигез булып муниципаль район Башлыгы урынбасарына, муниципаль районның контроль-хисап органы рәисенә карата муниципаль район Башлыгы күрсәтмәсе белән рәсмиләштерелгән хокукый акт, муниципаль районның контроль-хисап органы рәисе урынбасарына һәм муниципаль районның контроль-хисап органы аудиторларына карата муниципаль районның контроль-хисап органы рәисе боерыгы тора.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2022 елның 7 июлендәге
XXIII-3 номерлы карарына
Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2024 елның 30 июлендәге
L-2 номерлы карары
редакциясендә
кушымта №3

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи эш хаклары

| N п/п | Вазыйфаның аталышы | Вазыйфаи эш хакы, сумнарда |
|---|---|---|
| | | 8 төркем |
| 1. | Башкарма комитет җитәкчесе | 34640 |
| 2. | Совет аппараты җитәкчесе | 31443 |
| 3. | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 31176 |
| 4. | Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе | 31043 |
| 5. | Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары | 28512 |
| 6. | Башкарма комитет аппараты идарәсе башлыгы | 25314 |
| 7. | Мөстәкыйль бүлек башлыгы, Башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе (аппараты) башлыгы | 24248 |
| 8. | Башкарма комитет аппаратының идарә башлыгы урынбасары | 23982 |
| 9. | Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары, башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары | 21184 |
| 10. | Муниципаль район Башлыгы ярдәмчесе | 21184 |
| 11. | Башкарма комитет идарәсе составындагы бүлек башлыгы | 21184 |
| 12. | Сектор мөдире | 19585 |
| 13. | Баш белгеч | 18786 |
| 14. | Әйдәүче белгеч | 17454 |

Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи эш хаклары күләмнәрен билгеләү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен тиешле муниципаль берәмлек статусына һәм аның территориясендә даими яшәүче халык санына бәйле рәвештә хезмәт өчен түләү төркемнәренә кертү күрсәткечләре кертелә.

Күрсәтелгән күрсәткечләргә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге сигезенче төркемгә кертелгән – халык санына бәйсез рәвештә башка муниципаль районнар.

Муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенә вазыйфаи эш хакының күләме әлеге карар нигезендә билгеләнә. Шул ук вакытта айлык акчалата түләү күләме муниципаль район Башлыгына айлык акчалата түләүләрнең 0,6 күләменнән артык була алмый.